№53 (1093)
31 август
2006 ел

Көмеш кыңгырау

1996 елның 1 гыйнварыннан чыга башлады

Матурлык иҗат итәбез

Көз якынлаша. Аяк астында кыштырдаган сап-сары яфраклар, чикләвекләр, кипкән камыш картиналар, икебаналар, вазалар һ.б. ясау өчен менә дигән чимал. Форсатны ычкындырмагыз әле, бу китапчыкны укып чыгыгыз да эшкә тотыныгыз!



"Көмеш кыңгырау" остаханәсе

Тырышсаң – бар да була!

Агач яфраклары төрле төсләргә керә башлады инде: алсу, сары, кызгылт-сары. Ә чәчәкләрнең ниндие генә юк. Нәкъ менә шушындый хозур вакытта оста куллы балалар матур - матур чәчәк бәйләмнәре өчен нарат һәм чыршы күркәләре, кипкән үләннәр, төрледән - төрле үлән орлыклары, арыш башаклары, миләш тәлгәшләре, көнбагыш башлары әзерләп куялар. Күзгә гүзәллекне күрсәтү өчен, чәчәкләрне, яфракларны кочак - кочак җыярга кирәк түгел, билгеле. Гаҗәеп бормалы агач ботагы, сихри бер чәчәккә охшаган яфрак кәефне күтәрергә һәм табигатьнең экияти бер гүзәллеген ачарга мөмкин.

Табигать бүләк иткән чималлардан чәчәк бәйләмнәре ясау аранжировка дип атала. Ул үзенә бер осталык таләп итә, рәссам, сынчы сәнгате белән бер югарылыкта тора диярлек. Өй шартларында эшләнелә торган аранжировка өчен кыйммәтле чәчәкләр кирәкми.



Бакчада, урманда җыйган, тапкан үлән, ботаклар да ярый. Аларны тик булдыра алган кадәр тиз арада суга утыртырга кирәк. Очларын кисәргә, ботакларның һәм каты сабакларның очларын 2-3 сантиметр югарылыкта кисәргә кирәк (суны яхшырак "эчсен" өчен). Аранжировкага тотыныр алдыннан ярты - бер сәгать кала бар үсемлекләр дә тирән суда утырырга тиеш.

Шунысын истә тотыгыз: табигый чималдан эшләнгән аранжировкалар - ул үсемлекнең, вазаның һәм шушы күренешнең урнашуы тәңгәллеге. Әгәр синең матур агач ботагың яки эре чәчәгең (мәсәлән, гладиолус) булса, зур ваза кирәк булачак. Аны идәнгә яки тәбәнәк өстәлгә куйсаң матур була. Ә инде бер генә яфрактан яисә чәчәктән торган композиция ясыйсың килсә, кечкенә ваза яки үтә күренмәле бокал аласың һәм аны язу өстәленә йә китап киштәсенә куя аласың.



Менә шундый үзенчәлекле букетлар ясау өчен сиңа энәләр яки булавкалар, тимерчыбык, кәтүк җебе, бәрхет кәгазь, катыргы, тукыма кисәкләре, кайчы, бакча, басу чәчәкләре, җиләк - җимеш, орлыклар, кыяклы үсемлекләр, төрле зурлыктагы һәм рәвештәге вазалар, тәлинкәләр кирәк.

Чәчәк вазалары һәм кәрҗиннәр

Чәчәк вазалары
һәм кәрҗиннәр



Чәчәкнең нинди савытта, нинди төстә, формада булуы да бик мөһим. Үсемлектән торган бәйләмнәр өчен пыяла банкалар, шешәләр, хәтта салам эшләпәләр, балчыктан ясалган тәлинкәләр дә ярый.



Барысы өчен дә бер шарт: алар чиста булырга тиеш. Бактерияләр таратып тормасын өчен вазаларга кальций, камфора спирты, гөлсирин, нашатыр спирты яки марганцовка (бора кислотасы да ярый) салырга мөмкин. Су бик озак чиста булачак, димәк, чәчәкләр дә яхшы сакланачак.





СЕРЛӘР һӘМ...



Бертөрле үсемлекләр генә кулланганда, композиция матур булмый. Аларны төрле биеклектә, ераклыкта урнаштырырга кирәк. Әгәр инде берничә төрле чәчәк, ботак, яфрак, җиләк-җимеш кулланcаң, иң эресе, иң матуры алга чыгып, калганнары аны ямьләп торсын.



Файдалы киңәшләр

Чәчәкләр күзгә “карап торырга тиеш”. Эре чәчәкләрне һәм яфракларны вазаның алгы өлешенә, кечерәкләрен - өскәрәк; караңгы төстәгеләрен - аскарак, ачыкларын - өскә урнаштырырга кирәк.

Болай иткәндә ваза да егылмый, карарга да матур. Ботаклар, чәчәкләр һәм яфраклар барысы бер тигезлектә булмасын.

Төсләргә килгәндә, кызыл, сары һәм кызгылт - сары төсләр бер-берсен тулыландыралар, бәйрәм, шатлык, җылылык һәм яктылык хисе бүләк итәләр.



Яфрак яңгыры

Паркта, урманда матур яфраклар җыеп, иске журнал битләре арасына куеп яки үтүк белән киптерегез.

Ә хәзер "Яфраклар яңгыры" композициясе ясарга керешәбез. Агач ботагына яфракларны коелган, җилдә оча торган итеп беркетәбез. Подноска вак ташлар яки мүк җәябез, яфраклар, миләш тәлгәше, гөмбәләр, нарат күркәләре урнаштырабыз. Тамашачыга иң матур ягы белән каратып куябыз.



Суга иелгән таллар



Урманнан, парктан берничә матур ботак алып кайтыгыз. Түгәрәк яки озынча көзге, кечкенә вазалар, поднос яки тәлинкә әзерләгез. Көзгене яссы тәлинкә яки подноска куеп, кырларын мүк, ташлар яисә яфраклар белән бизәгез. Тигез өслекле матур гына "күл" барлыкка килер. "Күл"нең ярына ботаклар утыртылган ваза куябыз. Менә шул таллар "күл"нең өслегендә чагыла да инде.



Көзгегә портретлар







Көз портретын ясаганда озынча түгәрәк көзгенең кырларын башаклар яки яфраклы тал ботаклары (чәчкә охшатып) белән бизибез. Күз - җиләк яисә чәчәк, иреннәр - алма яки урталай киселгән яфрак. Башка банан, җир җиләге, петрушка яки чәчәк белән бизәлгән эшләпә кидерәбез.

Мондый портретны тукымада яки агачта эшләсәң, стенага да элеп була.

Гүзәл бәйләмнәр



- Вазага эре чәчәк (өчәү дә ярый) утыртабыз.
- Иркен итеп яфраклар яки ботак куябыз.
- Кечкенә детальлар өстибез (чия, башаклар, әкәм-төкәм кабырчыклары һәм башкалар)





Тыңлаучан җил

Көчле җил искәндә сыгылып төшкән кебек агач ботагы табыгыз. Тар муенлы, үтә күренмәле вазага утыртыгыз. Мондый савытта ботак нечкә, хәлсез күренәчәк. Ботакны туры итеп түгел, ә кыеклатып куегыз, очы вазаның стенасына тиеп торырлык булсын. Игътибар белән карагыз әле: бүлмәгә шаян җил үзе килеп кергән кебек, әйеме?



Натюрмортлар

Натюрмортлар

Натюрморт - иң ирекле, иң табигый аранжировка. Җиләк - җимешләрне вазаларга ничек урнаштырырга? Башта эреләрен яки иң матурын, аннан соң - кечерәкләрен. Төрле төстәге яфраклы ботакчыклар, күркәле нарат ботаклары, чистартылган үсемлек тамырлары, бүлмә гөлләре яфраклары белән бизәсәң, тагын да үзенчәлеклерәк була. Мондый натюрморт бәйрәм өстәле күрке дә, матур бүләк тә була ала.



Көмеш кыңгырау

Баш мөхәррир
Нәсимә САДЫЙКОВА

"Көмеш кыңгырау"ны гамәлгә куючы: "ТАТМЕДИА" массакүләм коммуникацияләр буенча Татарстан Республикасы агентлыгы.

"Көмеш кыңгырау" газетасы Татарстан республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 466нчы номерлы таныклык белән теркәлде.

Адрес: 423802, Чаллы шәһәре, ГЭС бистәсе, Гидротөзүчеләр урамы, 10нчы йорт, 429нчы бүлмә. "Көмеш кыңгырау" газетасы редакциясе. E-mail:komesh_k@List.ru

Җаваплылыгы чикләнгән "Глагол" ширкәте типографиясендә басылды. Язмаларның эчтәлеге һәм аларны газетада урнаштыруның сыйфаты өчен типография җавап бирми.

Басарга кул куелды 29.08.2006

Индекс - 31700
Тираж - 2850